| | | “Азык –төлек кибетенә тәм –томнар киледе” | Татар халык ашлары белән таныштыруны дәвам итү; кул чукларының физик үсешен ныгыту. Халык ашларына хөрмәт тәрбияләү. |
| февраль | I | “Кошлар җимлеккә очып килделәр” | Әвәләүдә гади торышны: гәүдәне аска, башны ияргә, иптәшеңнең эше белән үз эшеңне берләштерергә өйрәтү. Әвәләү алымнарының техникасын ныгыту. |
| | III | «Без кар бабайлар әвәләдек» | Төрле зурлыктагы шарлардан предмет ясый белүләрен ныгыту. Өлешләрнең чагыштырмача зурлыкларын күрсәтә белергә өйрәтү.Өйрәнелгән әвәләү алымнарын ныгыту.Эстетик үзләштерүне, форма хисен үстерү. |
| март | I | “Чынаяк(чокыр)” | Тәгәрәтү алымы белән савыт – саба әвәләргә өйрәтү. Кырыйларын тигезләп формага китерү. Өлешләрен беркетү һәм шомартуны ныгыту. Кул чуклары хезмәтен камилләштерү. |
| | III | «Кәҗә бәтие» | Балаларны дүрт аяклы хайван әвәләргә өйрәтү. (овал формасында гәүдә, баш, туры аяклар)Әвәләү алымнарын ныгыту:ике уч арасында тәгәрәтү,әвәләнгән гәүдәгә башка өлешләрен беркетү,шомарту,чеметү һ.б.) Тәҗрибәдән чыгып хәрәкәт,тойгы хисләрен үстерү. |
| апрел ь | I | “3 аюга савыт әвәләү” | Бер төрле формадагы предметларны, ләкин төрле зурлыктагы предметларны әвәләргә өйрәтү; предметларны әкият буенча драматизацияләргә өйрәтү. Савытларны әвәләүне күнектерү; тәгәрәтү, сыту; кырыйларын бармаклар белән күтәрүне эшкәртү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Чеби” | Төрле зурлыкчтагы шарлар әвәләү, бер-берсе белән тоташтыру, чеметеп койрык, томшык ясау |
| май | I | Ирекле | Иҗади һәм үзлегеннән эшләүне үстерүне ныгыту. Стек белән эшләргә өйрәтү. |
| | III | Ирекле | Иҗади һәм үзлегеннән эшләүне үстерүне ныгыту. Стек белән эшләргә өйрәтү. Алган белемнәрен куллануны ныгыту. |

***Җыр***

***Аңлатма язуы***

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында

## 2.5 «ФИЗИК ҮСЕШ»

***Сәламәтлек***

***Аңлатма язуы***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны

чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк- җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

## ЙОКЫДАН УЯНУ ГИМНАСТИКАСЫ

## Комплекслы-тематик план

| **ай** | **Гимнастика** |
|---|---|
| сентябрь | «Уяну»<br>Йокы качты тәрәзәдән, йөгерде юллардан,<br>Ә без синен белән уяндык, уяндык та елмайдык (киерелү)<br>Башта күзләрнен берсен ачтык, аннары икенчесен,<br>Кулларны күтәреп төшердек, велосипед әйләндердек.<br>Уңга-сулга борылдык, аннары сикереп тордык. |
| октябрь | «Хәерле иртә»<br>Хәерле иртә, күзләр. Сез уяндыгызмы?(күзләргә массаж. Бармаклар белән бинокль ясап, як-якка карыйлар)<br>Хәерле иртә, колаклар. Сез уяндыгызмы?(колакларга  массаж. Учны колакларга куялар (“Чебурашка”), як-якны тыңлыйлар)<br>Хәерле иртә, куллар. Сез уяндыгызмы?(кулларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Пропеллер” күнегүе)<br>Хәерле иртә, аяклар. Сез уяндыгызмы?( аякларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Велосипед” күнегүе)<br>Хәерле иртә, кояш. Мин уяндым!( кулларны сузып киерелү) |
| ноябрь | Әйдәгез, бергәләп, басабыз,<br>Кулларны ян – якка сузабыз.<br>Аннары бөгеләбез,бергәләп тураябыз.<br>Кулларны күтәрәбез,<br>Кояшка сәләм юллыйбыз.<br>Кулларны качырабыз,<br>Аннары аларны бергәләп эзлибез.<br>Уңга карыйк,<br>Сулга борылыйк.<br>Утырабыз, торабыз.<br>Үкчәгә дә басыбыз,<br>Аяк очларына басып, |

| | |
|---|---|
| | Кояшка үреләбез. |
| декабрь | «Без шулай итәбез»<br>Без йоклап тордык, бераз уйнарга булдык.<br>Башны иябез алга, уңга, сулга борабыз,<br>Аннан карап торабыз.<br>Иң өсләрен сикертәбез, кулларны биетәбез.<br>Бер алга, бер артка сузып,<br>Күңелле ял итәбез.<br>Аннары без чүгәлибез, тезләрне кочаклыйбыз.<br>Башны алга яшереп, без ападан качабыз. |
| январь | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”.  Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана ». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>4. “Пескәй сузыла”  Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| февраль | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үрелә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр)<br>Сәлам өләшә (сәлам бирәләр) |
| март | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр)<br>Аларны да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар)<br>Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Якты көнгә сокланып,<br>Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре) |

| | |
|---|---|
| | Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| апрель | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр)<br>Бик кыен түгел бу эш. |
| май | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр)<br>Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре)<br>ярга чыгалар. (сулыш алу күнегәләре) |

## Физик культура

***Аңлатма язуы***

«Физик культура» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда физик культурага кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү. Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү.Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету.Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен вариантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.

***Саф һавада хәрәкәтле уеннар***

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек

тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

## Комплексы-тематик план

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында»<br>”Куяннар һәм бүре” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | «Огуречик»<br>“Көтүче һәм көтү” | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычкан» | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Октябрь | I | “Ябалак” | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |
| | | “Төсле автомобильләр” | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |
| | II | “Кыңгырау” | Дус – тату уйнауны булдыру, түгәрәк тирәли сиганал буенча йөгерү күнекмәләрен, тизлекне үстерү, |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |
| | III | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | IV | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Көн-төн” | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру, сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | “Бүләкләр” | Балаларны бер-берсе белән аңлашып кирәк чакта ярдәм итеп уйнарга өйрәтүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | “Кайда шалтыраттылар” | Ишетү сәләтен үстерү,реакцияләренең тизлеген көчәйтү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | “Аучы һәм куяннар” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | “Мине куып җит” | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру. |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| январ | I | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Аксак төлке” | Бер аякта сикерү кәнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | “Кыш бабай” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | III | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| | | “Светофор” | Светофорның төсләре турындагы белемнәрен ныгыту, игътибарларын үстерү, уйлап эш итәргә өйрәтү. |
| март | I | “Кем әйберне тизрәк күчерә?” | Тизлек, сизгерлек үстерү, дус –тату уйнауны булдыруны дәвам итү,күрсәтелгән хәрәкәтләрне төгәл итеп башкарырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |
| | III | “Флагка кадәр сикер” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Төсләр сату » | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | IV | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| апрель | I | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Челән белән бакалар” | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| май | I | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Тупны, сикертеп, алып бар” | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | “Буш урын” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

## 3.Оештыру бүлеге

3.1. Төркемдә **көндәлек режим** балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп төзелгән.

| № | Режим моментлары | Үтәү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Балаларны кабул итү. Иртәнге фильтр.Уеннар. | 6.00-7.40 |
| 2. | Иртәнге гимнастика. | 7.40-7.45 |
| 3. | Иртәнге ашка әзерлек. | 7.45-7.50 |
| 4. | Иртәнге аш. | 7.50-8.05 |
| 5. | Белем бирү эшчәнлегенә әзерлек.Иртәнге түгәрәк. | 8.05 - 8.30 *(сиш.,пэнжешэмбе 8.50-9.30)* |
| 6. | Белем биру эшчәнлеге | 1)8.30-8.502)8.50-9.10<br>(Пәнҗешэмбе 11.00-11.20(урамда), сиш.,пәнҗеш.9.30-9.50) |
| 7. | Уеннар. Икенче иртәнге аш.Урамга чыгарга әзерлек. | 9.20-9.45 (сиш.8.50-9.45, сиш.,пәнҗешәмбе 9.50-10.05) |
| 8. | Урамда булу. | 9.45 -11.30 (сиш.,пәнҗ. 10.05-11.30 ) |
| 9 | Урамнан керү. Көндезге ашка эзерлек. | 11.30-11.50 |
| 10 | Көндезге аш. | 11. 50-12.10 |
| 11 | Көндезге йокыга әзерлек.Көндезге йокы. | 12.10-14.40 |
| 12. | Йокыдан тору.Чыныктыру чаралары. | 14.40-14.50 |
| 13. | Төштән соңгы аш. | 14.50-15.00 |
| 14. | Белем бирү эшчәнлегенә әзерлек | 15.00 – 15.15 |
| 15. | Түгәрәк эшчәнлеге. | 15.15-15.35 |
| 14. | Уеннар.Мөстәкыйл эшчәнлек. | 15.35-16.15 |
| 15. | Кичке түгәрәк.Кичке ашка әзерлек. | 16.15-16.35 |
| 16. | Кичке аш. | 16.35-16.55 |
| 17. | Уеннар.Урамда мөстәкыйль уеннар.Өйләренә озату. | 16.55-18.00 |

## 3.2 Оештырылган белем бирү эшчәнлеге

14 нче төркем Н.Е. Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе астындагы “От рождения до школы” программасы буенча эшли. Бу программа ФГОС таләпләренә туры китереп төзелгән. Шушы программадан чыгып төркемдә белем эшчәнлегенең атналык тематикасы төзелде:

| Тема | Вакыт |
|---|---|
| Мәктәп – белем йорты | 31.08.-04.09 |
| Исәнме, балалар бакчасы | 07.09- 11.09 |
| Көз байлыклары | 14.09-18.09 |
| Алтын көз | 21.09- 25.09 |
| Алтын көз | 28.09- 30.09 |
| Авылга әбигә кунакка | 01.10- 9.10 |
| Мониторинг | 12.10-16.10 |
| Минем сәламәтлек | 19.10- 23.10 |
| Мин һәм минем гаилә | 26.10-30.10 |
| Мин яши торган өй | 02.11 – 06.11 |
| Минем дуслар | 09.11- 13.11 |
| Кеше хезмәте өчен кирәкле җиһазлар | 16.11-20.11 |
| Үзеңне сакла | 23.11-30.11 |
| Нәрсә нәрсәдән һәм ни өчен? | 01.12-04.12 |
| Менә салкыннар килде һәм кыш җитте | 07.12-11.12 |
| Яңа ел якынлаша | 14.12 -18.12 |
| Яңа ел | 21.12-25.12 |
| Яңа ел | 28.12-31.12 |
| Кыш көне урман хайваннары | 11.01-16.01 |
| Салкын кайда яши? | 18.01-23.01 |
| Кар бөртекләре | 25.01-30.01 |
| Әкиятләр илендә | 01.02-06.02 |
| Минем яраткан шәһәрем | 08.02-13.02 |
| Мин, син, ул – дус дәүләт | 15.02-20.02 |
| Әти кебек булырга телим | 22.02-29.02 |
| Алтын куллы әбием | 01.03-05.03 |
| Халык бәйрәмнәре һәм гореф - гадәтләре | 07.02-12.03 |
| Минем туган ягым | 14.03-19.03 |
| Исәнме, яз! | 21.03-26.03 |
| Язгы маҗаралар | 28.03-31.03 |

| | |
|---|---|
| Мониторинг | 01.04-09.04 |
| Урманда – яз | 11.04-16.04 |
| Җир көне | 18.04-23.04 |
| Җир көне | 25.04-30.04 |
| Җиңү көне өчен сезгә зур рәхмәт! | 02.05-07.05 |
| Юл йөрү кагыйдәләре | 10.05-14.05 |
| Тиздән җәй | 16.05-21.05 |
| Саубул, балалар бакчасы | 22.05-29.05 |

3.3. ФГОС таләпләренә туры китереп оештырылган **белем бирү өлкәләре** түбәндәгечә:

| Оештырылган белем бирү өлкәләре | Саны | Искәрмәләр |
|---|---|---|
| Танып белү үсеше. | 2 | ФЭМП -1,<br>Тирә-юн белән таныштыру -1 |
| Сөйләм телен үстерү | 1 | |
| Рәсем<br>Музыка | 1<br>2 | |
| Физик үсеш (Физик культура, сәламәтлек) | 3 | 1 урамда |
| Әвәләү | 2 атнага 1 | Ябыштыру белән чиратлашып |
| Ябыштыру | 2 атнага 1 | (әвәләү белән чиратлашып |
| Барлыгы: | 10 | |
| Катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган өлеш | | |
| Өстәмә белем бирү | 2 | ата-аналар соравы буенча |
| Барлыгы: | 12 | |
| Режим барышында белем бирү эшчәнлеге | | |
| Иртәнге гимнастика | Көн дә | |
| Чыныктыру чаралары | Көн саен | Иртәнге гимнастика.Һава ванналары.Яланаяк йөрү. Акрынлап күтәрелеш, профилактик физкультура-сәламәтләндерү процедуралары |
| Гигиена процедуралары,КДН формалаштыру | Көн саен | |
| Иртәнге түгәрәк | Көн саен | аралашу (үсеш бирүче диалог формасында үткәрелә) |
| Вечерний круг | Көн саен | Узган көннең иң мөһим мизгелләре балалар белән рефлексия — |

| | | |
|---|---|---|
| | | фикер алышу формасында үткәрелә |
| Режим вакытында әңгәмә үткәрү | Көн саен | |
| Матур әдәбиятын уку | Көн саен | |
| Танып-белү үсеше –тикшеренү эшчәнлеге | атнага 1 тапкыр | |
| Конструктив-модель эшчәнлек, конструкцияләү | атнага 1 тапкыр | |
| Дежурлык | Көн саен | |
| Саф һавада булу | Көн саен | |
| Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | | |
| Ирекле уеннар | Көн саен | |
| Активлык үзәкләрендә балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Көн саен | |

3.4 ФГОС таләпләренә туры килгән белем өлкәләреннән чыгып, балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп, **атналык оештырылган белем бирү эшчәнлеге** төзелде

| | |
|---|---|
| **Дүшәмбе**<br>1.<br>2. | **Сишәмбе**<br>1.<br>2. |
| **Чәршәмбе**<br>1. Рәсем 8.30-8.50<br>2.Музыка 9.00-9.20 | **Пәнҗешәмбе**<br>1.<br>2. |
| **Җомга**<br>1.<br>2.<br>15.15-15.35 төзү (режим вакытында) | |

***3.5. МИЛЛИ ТӨБӘК БӘЙЛӘНЕШЕ (МТБ)***

***Аңлатма язуы***

**Тәрбияләү һәм белем бирү бурычлары:**

Туган йортка, балалар бакчасына, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Туган шәһәрнең күренекле урыннары белән таныштыру.

Татар халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.

Рус халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.
Үткән буын иҗат иткән барлык әйберләргә ихтирам тәрбияләү.

| № | Белем өлкәсе | Бурычлар |
|---|---|---|
| 1 | Физик үсеш | Хәрәкәткә, бергә уйналучы татар халык һәм рус хәрәкәтле уеннарына кызыксынучанлык тәрбияләү. Балада уңай сыйфатлар, татар һәм рус халкының сулыш гимнастикасын, физминуткаларын, күнегүләрен куллана алу күнекмәләрен формалаштыру. |
| 2 | | Татар һәм рус халкының хәрәкәтле уеннары белән танышу, халык уеннарына кызыксынучанлык уяту. Балаларның иҗади фикерләүләрен. Физик сыйфатларын: тизлек, осталык, чыдамлыкларын үстерү, хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерү. |
| 3 | Социаль-шәхси үсеш | Татарстан республикасы һәм Рәсәй турында беренче күзаллауларын формалаштыру..<br>Зурларга һәм яшьтәшләренә әдәпле эшдәшү, үзләрен алар белән тотнаклы тоту сыйфатларын тәрбияләү. Дуслык, дөреслек, кешелеклелек, геделлелек тәрбияләү. |
| 4 | | Үз-үзеңә үзлегеңнән һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтүне булдыру (зурлардан башка киенү, чишенү, киемнәрне төреп – элеп кую), төркемдә һәм балалар бакчасы җирлеген тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү. Үз шәһәрнең язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләрендә чагылган кешеләргә файда китерүче хезмәт төрләре турында күзаллауларын формалаштыру.<br>Үзлегеннән хезмәт итәргә һәм зурлар эшендә катнашу теләге белдергәнне бүләкләү һәм ныгыту. |
| 5 | | Хәвефле ситуацияләрдән чыгу юллары, беренче ярдәм күрсәтү алымнары белән таныштыру. Табигатьтәге хәвефле ситуацияләр (зарарлы үсемлекләр һәм гөмбәләр) турында белемнәрен формалаштыру.Туган шәһәр урамнарында юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту. |
| 6 | Сөйләм үсеше | Татар һәм рус фольклоры, туган шәһәр язучылары һәм шагыйрьләренең якты иллюстрацияле китаплары белән таныштыру. Әсәрләрне эмоциональ кабул итүне булдыру.<br>Геройларның характерын аңлый белү күнекмәләре формалаштыру. |
| 7 | | Балалар бакчасындагы националь культура тирәлеге аша туган телне һәм икенче телне өйрәнү күнекмәләре формалаштыру. Зурлар һәм яшьтәшләре белән сөйләшү теләге уяту. |
| 8 | Танып белү үсеше | Туган якның һәм Мәскәү шәһәренең күренекле урыннары, туган чкның үсемлекләре, хайваннары белән таныштыру. Татар һәм рус халкының мирасына кызыксынучанлык уяту. |
| 9 | Иҗади – эстетик үсеше | Халык уен кораллары: гармун, балалайка белән таныштыру. Татар халкының кайбер бию күнегүләрен башкарырга өйрәтү |
| 1 | | Татар халкының декоратив – кулланма сәнгатенә кызыксынучанлык уяту, татар орнаменты белән әйберләрне буярга өйрәтү. Иҗади –сәнгатьтә «Яфрак», «Тюльпан», «Кыңгырау чәчәге» орнаменты куллану. Городец эшләнмәләре белән танышу (бутон, купавка, розана, яфрак). Рәсемдә дымка бизәкләрен кулленуны ныгыту. |

| Ай | Физик үчеш | Социаль – коммуникатив үсеш | Танып белү, сөйләм үсеше | Иҗади –эстетик үсеш |
|---|---|---|---|---|
| **Түбән Кама, Татарстан** | | | | |
| Сентябрь Октябрь | *Уеннар:* «Скок - перескок», «Карусель», «Яшелчәләр» «Төсле автомобильләр» *Имитацион уен:*«Без автобуста барабыз» | Туган шәһәр турында сөйләшү. Заводлар турында *иллюстрацияләр карау.* *Әңгәмә:* «Минем Республикам Татарстан», «Шәһәр урамнары», «Транспортта үз-үзеңне әдәпле тоту» «Профессияләр» | *Әкиятләр.* «Аю һәм бабай», «Төлке һәм торна» Р. Батулла «Көчтәнәч» *Шигърият.* Б. Рәхмәт «Әтәчкәй...» Р.Валеева «Курчаккакүлмәк бүләк иттем» Р. Миннуллин «Әни белән эти турында» *Проза.* А. Хасанов «Балалар бакчасында», *Ятлау:*Бармак гимнастикасы «Бармаклар» | *Музыка:* «Осень наступила» Л. Шигабутдинова көе *Тыңлау:* «Әпипә» «Хороводная», «Әйдә, биибез» (диск «Шома бас»). *Иҗади сәнгать:* *Әвәләү:* «Кошлар», «Дустыма бүләк» *Рәсем:*«Шәһәр урамнарында», «Яулыкны бизибез» *Бәйрәм:*«Сөмбелә» |
| **Россия** | | | | |
| Ноябрь | *Уеннар.* «Диңгез шаулый», «Тавык һәм чебиләр». | Әңгәмә: «Минем илем», «Россия буенча сәяхәт», «Балаларның дусты - светофор» *Диактик уеннар.* «Три цвета светофора», «Балалар- җәяүлелеәр һәм балалар-пассажирлар». Рус халык әкичтләренә костюмнар әзерләү | *Әкиятләр.* «Мужик и медведь» «Дурак и береза» «Как варить компот?» Г. Юдин «Синие листья» В. Осеева *Шигърият.* «Котик» М. Дружинина, «Мы идем через дорогу» М. Дружинина, «Вот какой рассеянный» С. Маршак, «Дядя Степа» С. Михалков, «Светофор» С. Маршак **Проза.** «Сторож» В. Осеева, «Как Маша стала большой», «Осень на пороге» Н. Сладков | *Җыр.* «Осень» И.Кишко сүзләре, сл. Т.Волгина көе, бишек җыры «Баю-бай» М Красина көе, М.Черной сүзләре, «Ива» А.Князькова көе. И.Токмакова сүзләре, «Дождик» М.Красева көе, Н.Френкель сүзләре *Иҗади сәнгать.* *Әвәләү:* «Дымка аты» *Ябыштыру.*«Матрёшкалар» (коллектив эш) *Рәсем:*«Настяга сарафан» (дымка бизәге) *Бәйрәмнәр:* «Рус халык әкиятләре кичәсе», «Капустник». |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Декабрь | *Уеннар*<br>«Көн - төн»,<br>«У медведя во бору»,<br>«Светофор»,<br>«Җитез җәяүле»,<br>«Два Мороза» | *Әңгәмә.*<br>«Мәскәү шәһәре»,<br>«Россия турында сөйләшү»,<br>«Юлда үзеңне дөрес тоту»<br>*Дидактик уен*<br>«Мәскәүдән кунаклар», | *Әкиятләр.*<br>«Кораблик», (золотой серпок. М.: Малыш, 1994)<br>«Мороз и заяц»<br>«Сказка про Комара Комаровича» Д. Мамин-Сибиряк<br>*Шигърият*<br>«Живи, елочка!» И.Токмакова<br>«Белый снег пушистый» И.Суриков<br>*Проза.*<br>«Поход» А. Гайдар<br>«Светик-трехцветик» Т.Александровой (Веселые картинки. №6. 2003), «Как елку наряжали» Л.Воронкова | *Җыр.*<br>Рус халык музыкаль коралы «балалайка» белән танышу<br>«Песня о Родине» И.Дунаевский<br>«Моя Россия» Г.Струве көе, Н.Соловьева сүзләре<br>«Я по городу иду» А. Перескокова көе, Т.Антонова сүзләре<br>«Скоро Новый год» И.Арсеева көе, В.Татаринов сүзләре<br>«К нам приходит Новый год» В.Герчик көе, З.Петрова сүзләре<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү:* «Әкияти кош» (филимонов бизәге)<br>*Ябыштыру:* «Поясны бизәү» (филимонов бизәге)<br>*Рәсем:* «Рус кызының күлмәге» (филимонов бизәге)<br>*Бәйрәмнәр:* «Хушкиләсең, Яңа ел!» «Раштуа бәйрәме» |
| **Татарстан** | | | | |
| Январь | *Уеннар*<br>«Казлар аккошлар»,<br>«Песи һәм тычкан» | Казан шәһәре турында сөйләшү.<br>Казан шәһәренең күренекле урыннары турында рәсемнәр карау.<br>*Әңгәмә:* «Татар халык ашлары» «Сфетофор янында машиналар»<br>*Имитацион уеннар:* «Без автобуста» «Светофор сигналларына карап юл аша чыгу» | *Әкиятләр:*«Зирәк карга»<br>А. Гаффар. «Койрык»<br>А. Алиш. «Куркак белән батыр»<br>*Шигърият*<br>Г. 'Гукай. «Кышкы кич»<br>Ш. Галиев. «Автобуста»<br>Р. Валеева. «Кил тизрәк, яз!» Б. Рәхмәт. «Асия»<br>Х. Халиков. «Хәерле иртә»<br>*Проза:*А. Алиш «Эшче абый» | *Музыка:*татар халык музыкаль коралы «Гармун” белән танышу<br>«Попляши!», «Найди свою пару» (диск «Шома бас»)<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Татар халкының милли ризыгы чәк-чәк»<br>*Ябыштыру* «Мендәр чигәм»<br>*Рәсем:*«Сөлге чигәм»<br>*Бәйрәм*«Нардуган» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Россия** | | | | |
| Февраль | *Уеннар:* «Көтүче һәм көтү», «Төлке һәм тавыклар», «Үрдәкләр», «Укчы», «Чокыр аркылы сикер» | *Беседы:* «Рус телендә назлы сүзләр», «Минем туган телем», «Мин киенә беләм», «Солдат абый» «Ватанны саклаучылар көне». | *Әкиятләр:* «Төлке, бүре, аю», «Әтәч һәм ногыт борчагы» «Сказка про маму» С.Прокофьева<br>*Шигърият:* «Научу обуваться братца» Е.Благинина, «Мамин день» И.Токмакова, «Праздник мам» В.Берестов<br>*Проза.*<br>«Про снежный колобок» Н.Калинина, «Оля пришла в садик» В.Карасева, «Звезлолетчики» В.Бороздин | *Музыка:*«Сапожки скачут по дорожке» А.Филиппенко көе,Т.Волгина сүзләре, «Заинька пушистый»,«Путаница» Е.Тиличева көе, К.Чуковский сүзләре, «Кошечка» В.Витлин көе, Н.Найденова сүзләре,<br>«Бравые солдаты» А.Флиппенко көе, Т.Волгина сүзләре,<br>«Мамочка моя»А.Перескоков көе, С.Антонова сүзләре<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Аюлар өендә нәрсә бар?»<br>*Ябыштыру* «Тоз савытын бизәү» (городец бизәге)<br>*Рәсем* «такта бизәү»(городец бизәге)<br>*Бәйрәмнәр* «Масленица», «Муса Җәлил- татар шагыйре- герой». |
| **Татарстан** | | | | |
| Март | *Игры:*«Соры бүре», «Хәйләкәр төлке» | *Әңгәмә:*<br>«Татарстан хайваннары», «Туган ягым кошлары», «Мухомор гөмбәсе», «Минем туган урам»<br>*Кошларга җимлекләр әзерләү*<br>*Сюжетлы-рольле уен*нар: «Шофер», «Транспорт һәм җәяүлеләр» | *Әкиятләр:* «Ике ялкау»<br>Г.Тукай «Су анасы»<br>*Шигърият:* Ш. Маннур. «каз бәбкәләре», А. Рәшит «Кояшлы туган ягым»,<br>Г. Зәйнашева «Сабантуй»,<br>М. Җәлил «Мой пес», «Чишмә», «батыр куян», «Гөмбәләр»<br>*Проза:*<br>М. Хасанов «Кар ява»<br>Г. Тукай. «Кайсы вакыт була?» | *Музыка:* «Парный танец», «Подружились» (диск «Шома бас»)<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү* «Кошлар»<br>*Ябыштыру:*«Кызылтүшләр һәм песнәкләр»<br>*Рәсем:*«Татар әкиятләрендә хайваннар»<br>*Бәйрәм:* «Нәүрүз» |
| **Россия** | | | | |
| Апрель | *Уеннар* «Чыпчыклар», | *Әңгәмә:* «Туган як агачлары», | *Әкиятләр:*«Лисичка-сестричка и серый волк», «Зимовье зверей» | *Музыка.*<br>«Зима прошла» Н. Метлов көе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | «Казлар - аккошлар», «У медведя во бору | «Туган чкта үсүче чәчәкләр һәм үсемлекләр», «Урманда үзеңне тоту әдәбе», «Бүлмә гөлләрен тәрбиялибез» Дидактик уеннар«Очалар, сикерәләр, йөгерәләр», «Нинди агачтан?» | «Медведь и солнце» Н. Сладков, «Сороки» В. Осеева, «Сказка о перевернутой черепахе» М. Пляцковский, «Под грибом» В. Сутеев<br>*Шигърият:* «Весна» Г. Ладонщиков, «Посидим в тишине» Е. Благинина, «А что у вас?» С. Михалков, «Почему рассердилась бабушка?», «Белая береза» С. Есенин<br>*Проза.*«Аленький цветочек», «Хотела галка пить…»<br>Л. Толстой, «Памятник советскому солдату» Л. Кассиль, «Неслух» Н. Сладков<br>*Ятлау өчен:*«Одуванчик» Е. Серова, | М. Клокова сүзләре, «Ласточка»<br>А. Перескоковкөе, С. Антонова сүзләре, «Песенка львенка и черепахи»<br>Г. Гладков көе, С. Козлов сүзләре, «Апрель» П. Чайковский<br>*Иҗади сәнгать.*<br>*Әвәләү:* «Дымка әтәче»<br>*Ябыштыру:*«Урманда яз» (коллектив эш)<br>*Рәсем:*«Пасхаль йомыркаларын бизәү» (филимон бизәге)<br>*Бәйрәмнәр:* «Пасха», «Г. Тукай – бөек шагыйрь» |
| Май | *Күңел ачу:*<br>«Без уйнарга яратабыз» | *Әңгәмә:*<br>«Туган ягым-Татарстан» | *Әдәби викторина.* «Таныш әдәби әсәрләр буенча сәяхәт » | *Рәсемнәр күргәзмәсе.*<br>*Бәйрәм:* «Әйдәгез, дуслашыйк»,«Сабантуй». |

### *3.6 ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ*

| **Ай** | **Тема** |
|---|---|
| сентябрь | 1.Консультацияләр : “Һәр балада талант бар”, “Балага спор төре сайлыйбыз”, “Гаилә конфликты һәм балалар”, “Кичке уеннар”, “Кичке укуның файдасы”.<br>2. Белешмәлек “Әгәр чит илгә барсаң”<br>3. Газета “Балалар бакчасына рәхим итегез”<br>4. Ата – аналар җыелышы:<br>-«Юлларда куркынычсызлык»<br>- «Балаларда яхшы сыйфатлар тәрбияләү»<br>- «УМК».<br>5. Табип киңәшләре: “Вакцинопрофилактика”, “Компьютерның һәм телевизорның зыяны”, “Күзләр өчен гимнастика”<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| октябрь | 1.Консультацияләр : “Хәрәкәтле уеннарның бала организмы өчен файдасы”, “Бишек җырлары җырлыйбыз”, “Яссытабанлылыкны кисәтү”, “Ни өчен бала уенчыкларны җыярга теләми?”, “Сәләтле бала”. |

| | |
|---|---|
| | 2. Газета “Сәламәт булыгыз!”, “Тәрбияче апа – бәйрәмең белән!”, “Өлкәннәрне тәбриклибез һәм бәйрәм белән котлыйбыз!”<br>3. Өлкәннәрне бәйрәм белән котлау, балаларның үз куллары белән ясаган бүләкләрен бирү.<br>4. “Сөмбелә” бәйрәмен уздыру<br>5. Табиб киңәшләре: “Бабасыр”, “Балаланың гаиләдәге физик тәрбиясе”<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| ноябрь | 1.Консультацияләр :“Профилактик прививкалар”, “Музыкотерапия”, “чиратта торганда һәм транспортта барганда балалар белән уеннар”.<br>2. Газета “Бәйрәм белән, кадерле әниләр!”<br>3. “Әниләр” бәйрәме уздыру<br>4. Табип киңәшләре: “Салкын һава турында 5 төрле әти – әниләрнең күзаллаулары”, “Матур һәм сәламәт тешләр”, “Төркемгә чир керсә...”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Белешмәлек “Бала белән бергә уйныйбыз” |
| декабрь | 1.Консультацияләр : “Саф һавада йөрүнең файдасы”, “Әти –әни булу рәхәт ул”, “Сюжетлы-рольле уеннар аша балаларда туган телне үстерү”, “Өйгә уйный-уйный кайтабыз”.<br>2. Балалар өчен шугалак (тау) төзү.<br>3. Газета “Тәҗрибәләр үткәрәбез”, “Хуш киләсең, Яңа ел”<br>4. “Хуш киләсең, Яңа ел!” бәйрәме уздыру<br>5. Табип киңәшләре: “Салкын тиюдән саклану чаралары”, “Гәүдә төзелеше бозылуы”, “Саф һавада хәрәкәтле уеннар”<br>6. “Сюжетлы-рольле уеннар” күргәзмәсенә әзерлек һәм үткәрү.<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>8. Ата – аналар җыелышы: “Тәртип кагыйдәләре” |
| гыйнвар | 1.Консультацияләр : “Бармак уеннары”, “Юл һәм балалар”<br>2. Газета “Балаларның юл травматизмы сәбәпләре”, “Чыныктыру чаралары”.<br>3. Ачык ишекләр көне: мастер – класс “Йокыдан уяну гимнастикасы”, “Саф һавада уеннар”<br>4. Мастер –класс “Сәламәт булыйк: чыныктыру алымнары”<br>5. Рәсем конкурсы “Айболит киңәшләре”<br>6. Табип киңәшләре: “Гриппка каршы аромотерапия”, “Туберкулездан саклану”, “Яссытабанлылык булса, нишләргә?”<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| февраль | 1. Консультацияләр: “Ишетергә һәм тыңларга өйрәнәбез”. “Биибез дә, җырлыйбыз”<br>2. Газета “Изге Вәли көне”, “Бәйрәм белән әтием, абыем, бабам”<br>3. “Ватанны саклаучылар көне” бәйрәмен уздыру<br>4. Табип киңәшләре:“Отморожение», “Бала йокысы”, “Йокыдан уяну гимнастикасы”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |

| | |
|---|---|
| март | 1.Консультацияләр: “Тиктормас балаларга уеннар”, “Начар сүзлелек”, “Балаларның урамда уйнау җирлекләре”.<br>2. Рәсем конкурсы “Минем яраткан әкият героем”<br>3. “8март – халыкара хатын кызлар көне” бәйрәме уздыру<br>4. Табип киңәшләре: “Җил чәчәге авыруы”, “Авитаминоз”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| апрель | 1. Консультацияләр:«Витаминотерапия”, “Балалар алдыйлар”, “Беренче китаплар”.<br>2. Газета “Көлке көне”, “Космонавтика көне”, “Бөек татар шагыйре Г.Тукай”<br>3. Табип киңәшләре: “Тычканнар таратучы чирләр”, “Саф һавада йөрү бик файдалы”<br>4. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| май | 1.Консультацияләр: “Кояш, су һәм һава безнең дуслар”, “Музыкаль аптека”, “Балаларның җәйге ялы”, “Су белән уеннар”.<br>2. Газета “Без сезне мәңге онытмабыз!”<br>3. Рәсем конкурсы “Җиңү көне белән!”<br>4. Табип киңәшләре: “Талпан авыруы”, “Баланың күзләрен саклыйк”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Ата – аналар җыелышы: “Оптимистлар илендә” |

## *3.7.* Төркемдә үсүче фән-пространство мохитен оештыру.

Төркемдә белем һәм тәрбия бирү өчен уенчыклар һәм уен почмаклары бар.

***1. «Туган ягым - Татарстан» почмагы***

- Милли киемдәге курчаклар: татар малае һәм кызы, рус малае һәм кызы
- Габдулла тукай портреты
- Уеннар өчен битлекләр

***Дидактик уеннар***

- «Интеллект карта»

***Методик әсваплар һәм аудио кушымта***

- К.В. Закирова, Л.Р. Мортазина “Балачак – уйнап – көлеп үсзр чак”
- З.М. Зарипова, Р.С. Исаева “Үстерешле уеннар”
- К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина “Балалар бакчасында әдәп- әхлак тәрбиясе”
- З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова, А.Т.Миникаева “Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге”
- К.В. Закирова, Л.Р. Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”
- Татар телендә мультфильмнар
- Диск “Балалар һәм эти-әниләр өчен УМК буенча уеннар
- Диск “Әкиятләр”
- Аудио – китап “Татар әкиятләре”
- Диск “Шома бас”

- Диск “Танцы народов Поволжья”
- Диск “Луиза Батыр – Булгари. Бииләр итек - читекләр”

***Мәгълүмат әсбаплары***

- Татар язучылары һәм шагыйрьләре
- Татар халык сәнгате
- Әкиятләргә иллюстрацияләр
- Татарстан Республикасы турында белешмә
- Рәсәй турында белешмә
- Түбән Кама шәһәре турында белешмә
- Татарстан Республикасы шәһәрләре турында белешмә
- Трафаретлар / орнаментлар
- Идел буе халыклары уеннары
- Рәсәй, Татарстан геральдикасы һәм бәйрәмнәре
- Альбом “Минем туган ягым”

***Татар әдәбияты***

- Балалар өчен шигырьләр
- Л.А. Харисова, В.А. Гарипова “Ватаным Татарстан”
- Батулла “Бишек хикәятләре”
- М. Фәйзуллина “Чебиләр зарядкасы”
- Ә. Ситдыйкова “Серле дөнья”
- Ф.Сафин “Кошлар яратучы малай”
- Татар халык әкияте “Камыр Батыр”
- Татар халык әкияте “Саламторхан”
- Татар халык әкияте “Сак –сок”
- Г. Тукай “Тылсымлы сәхифәләр”
- Х. Халиков

***2. “Музыкаль» почмак***

***Уен кораллары***

- Барабан, агачтан пластмасстан эшләнгән маракас, металлофон, саксафон, гитара, бубен, кастонетта, колотушка, курай.

***Музыкаль- дидактик уеннар***

- “Күңелле-күңелсез”
- “Музыкаль уен кораллары”

***Ясалма уен кораллары***

- Микрофон, маракас

***3. “Кәеф” почмагы***

- Күрсәтмә әсбап “Кәеф театры”
- Өстәл театры“Кәеф театры”
- Коллективта бердәмлек оештыру уеннары картотекасы
- Театральләштерелгән уеннар картотекасы
- Психогимнастика
- Эмоциональ бушатылу “көзге”

***4. “Театр” почмагы***

- Өстәл пәрдәсе; өстәл, күләгә, таякчыклар һәм бармак театрлары, театр өчен битлекләр, киемнәр.
- Дидактик уен “Әкият геройлары”
- Лото “Әкиятләр”
- Күрсәтмә әсвап “киемнәр өчен бизәкләр”

***5. “ПДД” почмагы***

- Лото “Юл йөрү билгеләре” 2шт
- Дидактик уен “Сак бул, юл!”
- Күрсәтмә әсвап “Транспорт”
- Дидактик уен “Юл йөрү билгеләрен өйрәнәбез”
- Өстәл уены “Юл”
- Махсус тарнспорт
- Картотека “Транспорт”
- Папка “Балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү”
- Папка “Светофорны өйрәнәбез”

***Методик кулланма***

- Г.А. Галеева, С.М. Гаффарова “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү”
- Э.Я. Степаненкова, М.Ф.Филенко “Дошкольникам о правилах дорожного движения”
- В.Э.Рублях “Правила дорожного движения”
- Т.Шакирова “Юл хәрәкәте билгеләре”
- Табышмаклар “Занимательно о правилах дорожного движения»
- Транспорт турында шигырьләр

***6. “Физкультура ”почмагы***

***Уеннар картотекасы***

- “Күзләргә гимнастика ясыйбыз”
- “Сулыш гимнастикасы”
- “сәламәтләндерүче уеннар”
- “Хәрәкәтле уеннар”

- “Бармак гимнастикасы”
- “Сюжетлы– рольле уеннар”
- “Физминуткалар”
- “Санамышлар”
- “Җырлы – биюле уеннар”
- “Йога”
- “Чыныктыру»

***Күрсәтмә әсбаплар***

- “Кышкы спорт төрләре”
- “Җәйге спорт төрләре”
- “Спорт җиһазлары”

3.8 Материал –техник база.

***Җиһазлар***

- Туплар, скакалкалар, төсле тасмалар, шишкалар, шалтыравыклар, сыбызгы, бубен, качыклар, флаглар, кеглялар, обручлар, гантельләр, кольцеброслар.

***Ясалма чыныктыру җиһазлары***

- Массаж келәмчеге, пробкалардан эзләр һәм келәмчекләр, мунчаладан келәмчекләр, киндер сюрприз йомыркаларыннан канат һәм гантельләр, ясалма туплар (эчендә борчак)

***7. “Куркынычсызлык” почмагы***

***Методик кулланма***

- Т.А.Шорыгина “Беседы об этикете с детьми 5-8лет”
- Т.А.Шорыгина “Беседы о воде, о природе”
- Т.А.Шорыгина “Беседы о правилах пожарной безопастности”
- Т.А.Шорыгина “Беседы об основах безопастности с детьми 5-8лет
- Т.А.Шорыгина “Беседы о том, кто где живет”
- “Дөрес туклану”
- Папка “Янгын куркынычлыгы”

***Үстерүче уеннар***

- “Урамда куркынычсызлык”
- “Беренче ярдәм”
- “Өйдәге куркынычсызлык”
- “Ут белән уйнама”
- “Сәламәт бул”
- “Профессияләр”

- Лото “Бөтен эш тә яхшы”

***8. “Табигать” почмагы***

***Үстерүче уеннар***

- Табигать календаре
- Лото “Беренче предметлар”
- Лото “Йорт хайваннары”

“4нче ким”

- “Баллы-тозлы, ачы”
- “Хайваннар һәм аларның балалары”
- “Рәсемнәрне бер рәткә җый”
- “Табигать күчтәнәчләре”
- “Агачлар”
- «4 сезона»: кыш, яз, җәй, көз.
- «Экологик уеннар»

***Күрсәтмә әсваплар***

- «Рәсемнәр буенча хикәяләр төзү»: кыш, яз, җәй, көз.
- «һава торышы»
- «Ел фасыллары алгоритмы»
- «Хайваннар, җиләкләр, кошлар»
- «Агачлар, куаклар, гөмбәләр»
- «Безнең як кошлары»
- «Чәчәкләр»
- «Киемнәр»
- «Кошлар»
- «Җиһазлар»
- «Бүлмә гөлләре»
- «Гербарий»
- «Кызыл китап»
- «Чәчәкләр турында легенда»
- Муляжлар: җиләкләр, җиләк-җимешләр, яшелчәләр, кыргый һәм йорт хайваннары, җир-су хайваннары, бөҗәкләр.

***9. “Сөйләм үсеше” почмагы***

***Үстерүче уеннар***

- “Капма -каршы”
- “Мәгънә буенча аер”
- “4нче ким”

- “Рәсемнәр буенча хикәя яз”
- “Сюжетлар буенча хикәя төзе”
- “Матур сүзләр өйрәнәбез”
- “Табышмаклар”
- “Шигырьләр”
- «Сөйләм телен һәм уйлау сәләтен үстерүче уеннар»
- «Чиста сөйләшү күнегүләре»

***10. “Математика” почмагы***

- Үстерүче уен “Без саныйбыз”
- Лото “Төсләр һәм фигуралар”
- Дидактик уен “Төс һәм форма”
- Дидактик уен “Предметлар һәм контурлар”

Шулай ук төркем кибет, чәчтараш, гаилә, шифаханә, даруханә, транспорт, почта сюжетлы-рольле уеннар өчен җиһазлар һәм әсбаплар белән тулыландырылган.

***КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ:***

***Төп программалар:***


1. Комплексты программа «Туганнан мәктәпкә кадәр»Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А.
2. 64 нче "Сөембикә" балалар бакчасының төп белем бирү программасы.

Парциаль программалар:

1.Балалар бакчасы: Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы.-Казан:Раннур, 2003.

2. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти – әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ,2011. – 560 б.

3. Белем һәм тәрбия эшчәнлегенең перспектив программасы «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е. Веракса, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Уртанчылар төркеме.

4. Бондаренко Т.М.Балалар бакчасында физик-сәламәтләндерү эше - Воронеж: ИП Лакоценина Н.А.,2012

5. Закирова К.В., Мортазина Л.Р. "Әй уйныйбыз,уйныйбыз..."Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар:балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. –Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013. – 224 б.

6. Закирова К.В. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе:методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина – Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.-424 б.

7. Зарипова З.М. "Үстерешле уеннар:методик кулланма/З.М.Зарипова , Р.С.Исаева.-Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.-128 б.

8. Закирова К.В. "Әхлак нигезе-матру гадәт"(Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова.-Казан:Мәгариф,2004.-383б.

9. Закирова К.В., Мортазина Л.Р.Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак: методик кулланма.-Казан: Редакционно-издательский центр,2012

10. Күзәтүләр нигезендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әйләнә-тирә турында белем бирү.Нәҗметдинова Р.Ф

11. Комарова Т.С. "Занятия по изобразительной деятельности в детском саду» (Из опыта работы) . М., «Просвещение», 1978.

12.Комплексты белем бирү «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева. Уртанчылар төркеме - Волгоград:Учитель,2012Колесникова Е.В. «Математика для детей 4-5 лет», ФГОС таләпләренә туры килгән.

13. Кравченко И.В., Долгова Т.Л. балалар бакчасында күзәтү. Уртанчылар төркеме. Прогулки в детском саду. Методик кулланма – М.: ТЦ Сфера, 2011.

14. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда үзләрен хәвефсез тоту кагыйдәләренә өйрәтү дәресләре циклы. Методик күрсәтмәләр/ Авт.-төз.: Г.А.Галеева һ.б.-Казан:"Балаларның тормыш иминлеге фәнни үзәге"ДУ нәшрияте, 2010

15. "Туган телдә сөйләшәбез":методик әсбап/Ф.В.Хәзрәтова,З.Г.Шәрәфетдинова,И.Ж.Хәбибулина.-Казан:Инновацион технологияләр үзәге.-2013.-256 б.

16. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы.-РИЦ, 2012

17. Хрестоматия для дошкольников 4-5 лет/Сост. Н.П.Ильчук и др.-1-е издание.М., АСТ, 1997.

18. Юсупов Ф.Ю., Камалова З.Ф., Борһанова Р.А. "Гөлбакча".Балалар бакчалары өчен хрестоматия.1990

**Кушымта**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;

региональ якын килүне гамәлгә ашыру.